**Манзарас авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 21 сентябреннән** **№ 24**

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндеркүл авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы Киндер Күл авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Манзарас авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 4 октябренә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы Киндер Күл авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20Б адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Күл авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы Киндер Күл авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

«- суэтем башнясы территориясен коймалау, проект-смета документациясен эшләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Г. Хәбибуллина